**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**БЕДЕНЬГИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИДӘҢГЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 50-5-40, факс 50-5-40

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**28 .10. 2025** **№ 1**

**2026 елда гражданнарга үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бидәңге авыл җирлегенең Татар Бидәңгесе торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Бидәңге авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм::

1. Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Татар Бидәңгесе авылы, Вахитов урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан Бидәңге төп гомуми белем бирү мәктәбе бинасында, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бидәңге авыл җирлегенең Татар Бидәңге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 13 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бидәңге авыл җирлегенең Татар Бидәңгесе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасындагы студентлардан, күпбалалы гаиләләрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәт итәргә чакырылган гражданнардан тыш, 2026 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы? махсус хәрби операциядә катнашучылар (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр), иреклеләр) һәм аларның гаилә әгъзаларын, атап әйткәндә: ата-аналарны, ир белән хатынны, балигъ булган балаларны; һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Татар Бидәңгесе торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- Татар Бидәңгесе торак пунктында су чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын кору, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, Татар Бидәңгесе торак пунктындагы рөхсәтсез чүплекләрне бетерү?».

» КАРШЫ «РИЗА”

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бидәңге авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бидәңге авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче урынбасары** **Р.Р. Сәйфетдинов**